Республика Татарстан
САБИНСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ ГОРОДСКОЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» ноябрь 2024 ел № 193

Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитетының 30.12.2021 ел, №240 карары белән расланган торак урыннарына мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында " 15.08.2022 №1415 карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитетының «Торак урыннарга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында " 30.12.2021 ел, №240 карары белән расланган торак урыннарга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пунктының унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Төзелгән гаризаны формат-логик тикшерү гаризаның электрон рәвешендәге һәр кырын тутыру барышында орган билгели торган таләпләр нигезендә бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал гаризаның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында гаризаның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.»;

1.2. 2.6.1 пунктының 10), 15), 17), 18) пунктчаларында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Саба шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Р.Г. Гыйлманов